ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2023 г. Зеленодольск № 01-438

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау турында

2006 елның 2 маендагы«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен Зеленодольск муниципаль районы Советында гамәлгә ашыру максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен расларга (Кушымта).
2. Әлеге Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты Җитәкчесе И.М. Хантимеровка йөкләргә.

**М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Башлыгының
2023 елның 27 ноябрендәге
01-438 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советына (алга таба - ЗМР Советы) кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. ЗМР Советына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорда килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, шул исәптән: Интернет кабул итү бүлмәсенә яисә электрон почта аша җибәрелгән электрон хәбәрләр рәвешендә язмача, «Электрон хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән гражданнарны шәхси кабул итү барышында гамәлгә ашырыла.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау һәр яртыеллык йомгаклары буенча (хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр) Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты гражданнары мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Мөрәҗәгатьләрне анализлау электрон документ рәвешендә килгән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы һәм аның урынбасарлары шәхси кабул иткәндә, урыннарда шәхси кабул иткәндә гражданнар саны турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар тематикасы турында мәгълүматны, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый актлар һәм башка актлар турындагы мәгълүматны (булган очракта) үз эченә алырга тиеш.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау ачык мәгълүмат булып тора, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.